СӨЙ ГОМЕРНЕ. СӨЙ ХАЛЫКНЫ. СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ
ОБЩЕСТВЕННО ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга | №108 (7281) | 10 сентябрь, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен

## Укулар башланды

**Район халык мәгарифе бүлеге каршындагы уникенче педагогик классларда занятиеләр башланды.**

**Икенче ел инде бу класслар мәктәпкәчә учреждениеләр өчен кадрлар әзерли. Быел группага 40 лап шәкерт тупланды. Аларның күбесе эш белән укуны чиратлаштырып алып баралар. Занятиеләр исә теоретик белем бирү белән бергә балалар белән эшләүдә практик күнекмәләр булдыруны да максат итеп оештырыла.**

## Халык депутатларының Октябрь район Советының бишенче сессиясе турында

# ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

6 сентябрьдә халык депутатларының егерме беренче чакырылыш Октябрь район Советының бишенче сессиясе булды.

Сессия беренче көн тәртибе итеп 30 нчы Түбән Чаллы сайлау округы буенча 1991 елның 12 июнендә Октябрь район Советына сайланган депутат Әнәс Нәбиуллович Рәхмәтуллинның депутатлык вәкаләтләрен таныды.

Шуннан соң башкару-күрсәтмә бирү функцияләрен йөкләү турында карар кабул ителде.

Аннан соң сессиядә халык депутатларының Октябрь район Советы органнарының эшен оештыру мәсьәләләре каралды. Октябрь район Советы рәисенең беренче урынбасары итеп Владимир Васильевич БОГАТИКОВ, өч рәис урынбасарының икесе итеп Адлер Ибраһимович ГАЗИЗУЛЛИН һәм Галимҗан Шакирович НУРГАЛИЕВ сайланды.

Сессия шулай ук район Советы президиумы составын яңартты, совет бүлекләре һәм идарәләре, аларның җитәкчеләрен раслауны да карады.

Көн тәртибенең өченче, төп мәсьәләсе буенча «Халык депутатларының Нурлат шәһәр Советы башкарма комитетының коммуналь хуҗалыклар объектларын тагын да үстерү һәм аларның тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү буенча эше турында» доклад белән шәһәр Советы рәисе М.М. ФӘРРАХОВ чыкты. Доклад буенча фикер алышуларда «Нурлатнефть» НГДУсы начальнигы депутат М. М. ХУҖИН, Бөтенроссия сукырлар җәмгыятенең район оешмасы рәисе Ф. Н. ХАҖИМОРАТОВ, шәһәрнең 1 нче мәктәп укытучысы депутат А. Ф. НИКОЛАЕВ, район үзәк больницасы баш врачы депутат З. А. ШАБАЕВ, Егоркино авыл Советы рәисе Л. Ф. БЕЛОВ, күптармаклы производство предприятиесе начальнигы Ф. И. ГАЙНУЛЛИН, җылылык челтәре начальнигы Р. Г. ХӘСӘНОВ иптәшләр катнаштылар.

Сессия әлеге көн тәртибе буенча тиешле карар кабул итте. Аннан соң районны газлаштыру буенча Октябрь район Советы рәисенең беренче урынбасары В. В. БОГАТИКОВ информациясе тыңланды. Сессиядә халык депутатларына бирелгән наказларның үтәлеше барышы турында информацияне район Советы рәисе урынбасары Г. Ш. НУРГАЛИЕВ ясады.

Сессиядә халык депутатларының район Советы план-бюджет комиссиясе составына депутат Әнәс Нәбиуллович РӘХМӘТУЛЛИН кертелде.

Соңгы көн тәртибе итеп сессия халык депутатларының Октябрь район Советы президиумының фермер (крестьян) хуҗалыклары оештыру буенча карарларын раслады.

Сессия эшендә район Советы депутатларыннан тыш ТССР халык һәм шәһәр, авыл Советы депутатлары, колхоз, совхоз, предприятие, оешма, җәмәгать оешмалары, кооперативлар, кече предприятиеләр, фермер хуҗалыклары җитәкчеләре катнашты.

## Халык депутатларының Октябрь район Советы

# КАРАРЫ

**Халык депутатларының Октябрь район Советы органнары эшен оештыру турында**

Халык депутатларының Октябрь район Советы карар кылды:

Башкару-күрсәтмә бирү властен көчәйтү максатыннан, Татарстан ССРның «Татарстан ССР да халык власте нигезләре турында» Законына нигезләнеп, башкару-күрсәтмә бирү функцияләрен тормышка ашыруны халык депутатларының район Советы президиумына йөкләргә.

## Халык депутатларының район Советы

# президиумы карары

**Совет рәисе Х. Х. МОРАДЫЙМОВ:** гомуми җитәкчелек һәм авыл хуҗалыгы, финанслар, дәүләт страхованиесе, налог инспекциясе, банк эшчәнлеге, экономика, җир, экология, кадрлар һәм махсус эшләр, җәмәгать тәртибен саклау, янгын куркынычсызлыгы, социаль законлылык, гражданнар оборонасы мәсьәләләре белән шөгыльләнә.

**Совет рәисенең беренче урынбасары В. В. БОГАТИКОВ:** капиталь төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, газ хезмәте, транспорт һәм элемтә, төзелеш оешмалары, электр челтәре эшчәнлеге өчен җаваплы.

**Совет рәисе урынбасары Т. А. НАЗАРОВА:** даими комиссияләр, депутатлар эшчәнлеге, эш белән идарә итү (хуҗалык мәсьәләләреннән тыш), ЗАГС, архив, бүләкләүләр мәсьәләләре өчен җаваплы.

**Совет рәисе урынбасары А. И. ГАЗИЗУЛЛИН:** юл төзелеше, сәламәтлек саклау, халык мәгарифе, культура, видеоберләшмәләр, яшьләр, физкультура һәм спорт, социаль тәэминат, җәмәгать оешмалары эшчәнлеге өчен җаваплы.

**Совет рәисе урынбасары Г. Ш. НУРГАЛИЕВ:** экономика бүлеге, сәүдә, көнкүреш хезмәте, җирле производство, ТНП, кооперативлар эшчәнлеге өчен җаваплы.

**БҮЛЕКЛӘР һӘМ ИДАРӘЛӘР:**

авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, финанс, эчке эшләр, халык мәгарифе, культура, экономика, социаль-тәэминат бүлекләре, оештыру, Советлар эшчәнлеге мәсьәләләре буенча, архитектура һәм шәһәр төзелеше, капиталь төзелеш һәм социаль-көнкүрешне төзекләндерү, яшьләр эше, физкультура һәм спорт буенча, эшләр белән идарә итү бүлекләре, юл-ремонтлау-төзү идарәсе, тармакара производство предприятиесе, ЗАГС бюросы, хезмәт һәм аңа урнаштыру бюросы.

## Халык депутатларының Октябрь район Советы

# КАРАРЫ

**Халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы составындагы үзгәрешләр турында**

Халык депутатларының Октябрь район Советы карар кылды:

1. Халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы составына түбәндәге иптәшләрне кертергә:

ГАЗИЗУЛЛИН Адлер Ибрагимович—халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе урынбасары.

НУРГАЛИЕВ Галимҗан Шакирович—халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе урынбасары.

2. Халык контроленың Октябрь район комитеты бетерелү сәбәпле, Фатыйх Миңнеханович Галимовны халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы члены вазифаларыннан азат итәргә.

## Халык депутатларының район Советы

# КАРАРЫ

## Халык депутатларының Октябрь район Советы бүлекләре һәм идарәләре һәм аларның җитәкчеләрен раслау турында

Халык депутатларының Октябрь район Советы халык депутатларының Октябрь район Советы башкарма комитетының түбәндәге бүлекләрен һәм идарәләрен бетерергә карар итте: агропромышленность, финанс, эчке эшләр, халык мәгарифе, культура бүлекләре, план комиссиясе, социаль-тәэминат, төзелеш һәм архитектура эшләре, капиталь төзелеш һәм социаль көнкүреш, төзелеш, хезмәт һәм социаль мәсьәләләр, физкультура һәм спорт мәсьәләләре, эш белән идарә итү, юл ремонтлау-төзү идарәсе, күптармаклы производство предприятиесе, ЗАГС.

Халык депутатларының Октябрь район Советының түбәндәге бүлекләре һәм идарәләрен оештырырга: авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, финанс, эчке эшләр, халык мәгарифе, культура, экономика, социаль тәэминат бүлекләре, оештыру, Советлар эшчәнлеге мәсьәләләре буенча, архитектура һәм шәһәр төзелеше, капиталь төзелеш һәм социаль-көнкүрешне төзекләндерү, яшьләр эше, физкультура һәм спорт буенча, эшләр белән идарә итү бүлекләре, юл-ремонтлау-төзү идарәсе, тармакара производство предприятиесе, ЗАГС бюросы, хезмәт һәм аңа урнаштыру бюросы.

Башка эшкә күчү сәбәпле, Р. Р. Вәлиевны район Советы башкарма комитетының управляющие вазифаларыннан азат итәргә.

Пенсиягә китү сәбәпле, Т. Л. Сиплатованы ЗАГС бюросы мөдире вазифасыннан азат итәргә.

Район Советының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек бүлеге начальнигы итеп Әнәс Нәбиуллович РӘХМӘТУЛЛИН, финанс бүлеге мөдире итеп Рәшит Габдрахманович БИЛАЛОВ, эчке эшләр бүлеге начальнигы итеп Владимир Викторович ИВАНОВ, халык мәгарифе бүлеге мөдире итеп Нәбиулла Хәйруллович АБДУЛЛИН, культура бүлеге мөдире итеп Рафик Хаҗипович МОРАДЫЙМОВ, экономика бүлеге мөдире итеп Галимҗан Шакирович НУРГАЛИЕВ, социаль тәэминат бүлеге мөдире итеп Лидия Николаевна ДИЛМӨХӘММӘТОВА, оештыру бүлеге мөдире итеп Фәрит Шәяхмәтович ГАЛИМОВ, Советлар белән эшләү бүлеге мөдире итеп Галина Валентиновна МАЛИКОВА, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге мөдире итеп Людмила Федоровна БАТЫРШИНА, капиталь төзелеш һәм социаль-көнкүрешне төзекләндерү бүлеге мөдире итеп Юрий Петрович КУЗНЕЦОВ, яшьләр эше, физкультура һәм спорт бүлеге мөдире итеп Флюра Рәшитовна НОГМАНОВА, управляющий итеп Владимир Иванович ТРЕМБОВИЦКИЙ, юл ремонтлау-төзү идарәсе начальнигы итеп Анатолий Кузьмич САВИНОВ, күптармаклы производство предприятиесе начальнигы итеп Фәрит Исламович ГАЙНУЛЛИН, ЗАГС бүлеге мөдире итеп Алевтина Яковлевна МАТРОСОВА, хезмәт һәм хезмәткә урнаштыру бюросы мөдире итеп Роза Абдулловна ӘХМӘТСӘГЫЙРОВАны расларга.

